# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Сәрдегән авылы торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2024 елның 14 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегенең Сәрдегән торак пунктында халык җыены карар бирде:

1. «90% куләмендә ташлама билгеләнгән I группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветераннары, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләр, ялгыз яшәүче 80 яшьтэн узган өлкән кешеләрдән, торып укучы студентлардан, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарны, контракт буенча хезмэт итуче һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Салавыч авыл җирлегенең Сәрдегән авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2025 нче елда үзарасалымны 600 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- торак пункт территориясен төзекләндерү:

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су үткәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су ташуны һәм бирүне, аны чистартуны, транспартировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инжнер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Салавыч авыл җирлеге Советының мәгълүмәти стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarctan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе Р.К.Латипов